ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«09» ноябрь 2020 ел № 357

2021 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының сәнгать-эстетик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары һәм «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Кушымта итеп бирелгән 2021 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарны расларга.
2. Сәнгать-эстетик юнәлештәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнарга карата 0,5 күләмендә төзәтмәләр коэффициентын билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарның 1 пунктында расланган норматив чыгымнар нигезендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru).
5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Башкарма комитетынын
09.11. 2020 ел, № 357
карары белән расланган

**2021 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының сәнгать-эстетик юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар (1 укучы балага бер елга сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | өч еллык уку вакыты | Дүрт еллык уку вакыты | Биш еллык уку вакыты | Җиде еллык уку вакыты | башлангыч һөнәри юнәлеш бирү |
| Музыкаль сәнгать | Шәһәр җирлеге | | | 55 793 | 64 719 | 84 130 |
| Музыкаль сәнгать | Авыл җирлеге | | | 60 519 | 70 105 | 90 982 |
| Сынлы сәнгать | Шәһәр җирлеге | | 30 808 | | 26 803 | 64 347 |
| Сынлы сәнгать | Авыл җирлеге | | 33 235 | | 28 980 | 69 559 |
| Хореография сәнгате | Шәһәр җирлеге | | | 58 474 | 48 228 | 175 835 |
| Хореография сәнгате | Авыл җирлеге | | | 63 795 | 52 609 | 191 884 |
| Гомуми эстетик сәнгать | Шәһәр җирлеге | | | 25 592 | | |
| Гомуми эстетик сәнгать | Авыл җирлеге | | | 27 818 | | |
| Фольклор сәнгате | Шәһәр җирлеге | | | 55 174 | 52 945 | 85 700 |
| Фольклор сәнгате | Авыл җирлеге | | | 60 079 | 57 660 | 93 239 |
| Эстрада-джаз сәнгате | Шәһәр җирлеге | 84 971 | | 81 330 | | 134 297 |
| Эстрада-джаз сәнгате | Авыл җирлеге | 92 265 | | 88 340 | | 145 742 |
| Театр сәнгате | Шәһәр җирлеге | 43 848 | | 40 718 | 40 728 | 64 463 |
| Театр сәнгате | Авыл җирлеге | 47 585 | | 44 206 | 44 213 | 69 610 |